**УКАЗ**
ПРЕЗИДЕНТА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ПРЕЗИДЕНТЫ
**УКАЗЫ**

# Өч яшьтән алып җиде яше тулган балаларга айлык акчалата түләү турында

Балалы гаиләләргә дәүләт ярдәменең өстәмә чараларын гамәлгә ашыру максатларында **карар бирәм:**

1. 2020 елның 1 гыйнварыннан Татарстан Республикасында Россия Федерациясе Президентының «Балалы гаиләләргә дәүләт ярдәменең өстәмә чаралары турында» 2020 елның 20 мартындагы 199 номерлы Указында каралган өч яшьтән алып җиде яше тулган балаларга айлык акчалата түләүне, бала туу һәм бала тәрбияләү белән бәйле рәвештә Татарстан Республикасы законнарында билгеләнгән пособиеләр, түләүләр һәм социаль ярдәм күрсәтүнең башка чараларын саклап калган хәлдә, билгеләргә.

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына:
2020 елның 1 маена кадәр айлык түләүләр билгеләнгән очракта, алар гаиләнең кереме дип саналмавын исәпкә алып, айлык акчалата түләү тәртибен һәм шартларын расларга;
ел саен Татарстан Республикасы бюджетында, шулай ук 2020 елга да, айлык түләүләр белән бәйле чыгымнарны финанслау чараларын билгеләргә;
дәүләт хезмәтләре күрсәтүче органнарның, муниципаль хезмәтләр күрсәтүче органнарның, башка дәүләт органнарының, җирле үзидарә органнарының, дәүләт органнары һәм җирле үзидарә органнарының ведомство карамагындагы оешмаларның айлык түләүләр билгеләү өчен кирәкле документларны (белешмәләрне), шул исәптән электрон рәвештә дә, бирүен тәэмин итәргә;
гражданнарның айлык түләүләр билгеләү буенча Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәкләре яисә «Дәүләт һәм муниципаль хезмәт күрсәтүләр (функцияләре) бердәм порталы)» федераль дәүләт мәгълүмат системасы яисә «Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталы» республика дәүләт мәгълүмат системасы аша, шул исәптән алардан әлеге пунктның

дүртенче абзацында күрсәтелгән органнар һәм оешмалар карамагындагы документларны таләп итмичә, мөрәҗәгать итү мөмкинлеген тәэмин итәргә.

3. Әлеге Указ аңа кул куйган көннән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы Президенты** **Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2020 ел, 08 апрель
№ ПУ-227